ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2021 г.Лениногорск № 1160

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 703 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 18 сентябрендәге 1574 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү һәм күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштыру турында кабул итү комиссиясе тарафыннан актны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге өстәмәләр кертергә:

2.16.1 пунктны пунктчалар белән тулыландырырга:

«ж) органга (оешмага) кабул итүгә язылу, хезмәт күрсәтү турында запрос бирү өчен (алга таба-запрос) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба-күпфункцияле үзәк), шулай ук хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган очракларда, әлеге запросны күрсәтелгән кабул итүгә бер үк вакытта язылып, бирү мөмкинлеге; (үз көченә 2022 елның 22 мартыннан керә)

з) муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантын билгеләү максатларында, мөрәҗәгать итүченең билгеләренә туры килә торган анкеталаштыру (мөрәҗәгать итүчегә сораулар исеемлеген һәм аларга тулы җаваплар вариантлары исемлеген күрсәтү);

и) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында каралган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантын күрсәтү.».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорскские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет - сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары А.Ю.Корноуховка йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М.Галимова
5-44-72